ИШЕКЛӘР АЧЫЛА

Яңа уку елында Татарстанда 11 яңа мәктәп эшли башлый

> 2

ӘГЕРҖЕ КИЛӘЧӘГЕ

Үзенчәлекле район башлыгы белән өмет һәм ниятләр турында әңгәмә

> 3

ЯҢА НИГЕЗ

Бу гаиләнең язмышы укучыларыбызны битараф калдырмады

> 3

«ҖИЛ АРТЫННАН»

Әлмәт театры башкалада яңа спектакль күрсәтәчәк

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 122 (28895) | Сишәмбе | 23 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Соңгы бер айда Россиядә бирелгән автокредит күләме арткан. Белгечләр моны төп ставканың төшүе белән аңлата. Яшерен-батырын түгел, автокредит рәсмиләштергәндә авыз пешү очраклары да еш күзәтелә. Кыен хәлдә калмас өчен, машинага кредит рәсмиләштергәндә нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләде.

Июнь аенда Россия халкы машина сатып алуга 71,1 миллиард сум акча сарыф иткән. «Автостат» аналитик агентлыгы белгечләре шулай дип ышандыра. Бу май ае белән чагыштырганда 38 процентка күбрәк. Җәйнең беренче аенда илдә барлыгы 29,4 мең яңа машина сатылган. Бу шул ук май ае белән чагыштырганда 36 процентка күбрәк. Ул айда Россиядә барлыгы 21,6 мең өр-яңа «тимер ат» сатылган булган. Әмма бу саннар узган елгы күрсәткечләр белән чагыштырганда бик аз, ди белгечләр. Бер ел эчендә Россиядә сатылган яңа машиналар саны 82 процентка азайган.

Соңгы айларда илдә сатылган өр-яңа «тимер ат»ларның күпчелеген Кытайда җитештерелгән машиналар тәшкил итә. «Автостат» аналитик агентлыгы белгече Азат Тимерханов, бүгенге шартларда моңа аптырыйсы юк, дигән фикердә. «Кытай безнең илгә каршы кертелгән чикләүләргә кушылмады, шуңа күрә анда җитештерелгән машиналар безгә әле дә кайтарыла. Санкцияләрне Корея да хупламады. Әмма логистика белән кыенлыклар килеп чыгу, машина җыйганда кирәкле детальләр җитмәү аркасында аларның машиналары азрак сатыла», – дип сөйләде «ВТ» хәбәрчесенә Азат Тимерханов.

Илдар Мөхәммәтҗанов

БУРЫЧЛЫ ТӘГӘРМӘЧ

МАШИНА АЛГАНДА ОТТЫРМАС ӨЧЕН НИ ЭШЛӘРГӘ?

Яңа машиналар күбрәк сатыла башлау белән Россиядә бирелгән автокредит күләме дә арткан. Саннар теленә күчсәк, июль аенда ил халкы машиналы булу өчен 46,8 мең кредит алган. Россиянең кредит тарихлары бюросы мәгълүматларына караганда, монысы алдагы айда бирелгән автокредитларга караганда 16 процентка күбрәк. Татарстанда арту 18 процентны тәшкил итә. Июль аенда республикада 2,3 мең автокредит бирелгән. Иң күп автокредит бирелгән төбәкләр исемлегенә Мәскәү (2,9 мең автокредит), Мәскәү өлкәсе (2,6 мең) һәм Санкт-Петербург кергән. Татарстан – дүртенче урында.

«Автокредит базары җанлану төп ставкадагы үзгәрешләргә бәйле. Хәтерләсәгез: яз көне Үзәк банк төп ставканы кисәк кенә 20 процентка күтәреп куйган көннәрдә Россиядә рәсмиләштерелгән автокредит саны да кимеде. Апрель аенда, төп ставка бераз төшү белән, илдә бирелгән автокредит күләме дә акрынлап арта башлады», – ди Азат Тимерханов.

Яшерен-батырын түгел, автокредит барлык төр кредит сазлыклары арасында иң мәкерлеләрнең берсе санала. Аны рәсмиләштерүчеләр арасында отучыларга караганда, оттыручылар күбрәк. Казандагы билгеле бер автосалонда автокредит рәсмиләштергән кешеләрнең күбесе әле бүген дә суд юлын таптый. Автокредит рәсмиләштергәндә ничек алданмаска? Нәрсәләрне истә тотарга кирәк? Шушы сорауларыбызга юрист Илнур Гарипов ачыклык кертте.

«РГС банк» тарафыннан уздырылган тикшеренү нәтиҗәләренә ышансаң, автокредит ярдәмендә машиналы булырга җыенган россиялеләрнең 79 проценты иң беренче чиратта аның процент ставкасына игътибар итә. «Беренче карашка, бу – гадәти хәл. Әмма автокредит рәсмиләштергәндә килешүнең энәсеннән җебенә кадәр яхшылап өйрәнергә, анда язылган өстәмә пункт, бүлекләргә дә игътибар итәргә кирәк. Счет алып барган өчен комиссия, ОСАГО, КАСКО, кредит алучының гомерен һәм сәламәтлеген иминиятләштерүгә булган таләпләр төрле банкта төрлечә. Шуңа күрә беренче карашка бик отышлы кебек тоелган автокредит та, бөтен нечкәлекләрен исәпкә ала башлагач, бермә-бер кыйммәткәрәк төшәргә мөмкин. Автокредит рәсмиләштергәндә алданган кешеләрнең күпчелеген, нигездә, әнә шул килешүне җентекләп өйрәнмичә генә имзалаган кешеләр тәшкил итә», – ди юрист.

Ахыры 3 нче биттә >

Билгеле булганча, Россиядә машинаны ташламалы шартларда алырга мөмкинлек бирүче махсус дәүләт программалары эшли. Быел аларны тормышка ашыру өчен 20,7 миллион сум акча бүлеп бирелгән. Ташламалы автокредит программасыннан беренче тапкыр машина алучы яки балигъ булмаган баласы булган кешеләр файдалана ала. Ташламалы автокредит вакытында дәүләт машина хакының 10 процентын каплый. Элегрәк әлеге программа буенча чит ил машиналарын да алып булса, хәзер исә ул үзебездә җитештерелгән машина сатып алганда гына бирелә. Аерым алганда, хәзер әлеге программа кысасында үзебездә җитештерелгән «УАЗ», «АвтоВАЗ», «ГАЗ», «УРАЛ» машиналарын 25 процент ташлама белән сатып алырга мөмкин.

КФУга ректор билгеләнде

Ленар Сафин 5 елга Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры итеп билгеләнде. Бу хактагы карарны Россия Премьер-министры Михаил Мишустин имзалады.

Исегезгә төшерәбез: Ленар Сафин 2010 елдан республиканың транспорт һәм юл хуҗалыгы министры вазыйфасында эшләде. 2020 елның сентябрендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов аны Федерация Советында үзенең вәкиле итеп билгеләде. КФУның Күзәтчелек советы Сафинны быел 24 мартта вуз ректоры вазыйфасына тәкъдим итте.

Ленар Сафин 1969 елның 11 февралендә Арчада туган. 1993 елда «хокук белеме» белгечлеге буенча Казан дәүләт университетын тәмамлаган. Казан финанс-икътисад институтының (КФЭИ) тарих һәм хокук кафедрасында ассистент булып эшли. 1995 елдан КФУда хокук юнәлеше буенча лекцияләр алып бара. 1998 елда исә җинаятьчелек хокукы һәм криминология кафедрасы доценты була. 2004 елда юридик фәннәр буенча кандидатлык диссертациясе яклый. Моннан тыш, Ленар Сафин КФЭИда менеджмент белгечлеге буенча икенче югары белем ала.

Кызлар кыйммәткә төшә

Казанда баланы мәктәпкә әзерләү чыгымы узган елдагыга караганда 17 процентка артып, уртача 11,9 мең сум тәшкил иткән. 2021 елда ата-аналар бу максатка якынча 10,2 мең сум тоткан булган. Яңа уку елына әзерләнү елдан-ел кыйммәтләнә. SuperJob сервисы үткәргән сораштыру нәтиҗәләре шуны күрсәтә.

Россия буенча да мәктәп кирәк-яраклары бәясе үсү күзәтелә. Миллионлы шәһәрләрдә үсеш Казандагы кебек – 17 процент. Белем йортына җыену чыгымнары Мәскәүдә барысына караганда да зуррак – 14,3 мең сум. Санкт-Петербургта яшәүчеләр уртача 13,1 мең сум сарыф иткән. Екатеринбургта – 12 мең сум. Пермь һәм Уфада бу максатка якынча 11әр мең сум тотылган. Ата-аналар әйтүенчә, узган елның август аендагы белән чагыштырганда, мәктәп әйберләре Санкт-Петербургта аеруча нык кыйммәтләнгән (31%). Башкалада да уку кирәк-яраклары хакы 30 процентка арткан.

Татарстанстат белгечләре баланы беренче сыйныфка әзерләү чыгымнарын исәпләп чыгарган. Малайлар кызлар белән чагыштырганда 3 мең сумга арзангарак төшә икән. Малайны беренче класска әзерләү чыгымы – уртача 18,8 мең сум, ә кызларны әзерләү 21,8 мең сум тәшкил иткән. Мәктәп өчен иң мөһим әйберләр (кием-салым, аяк киеме, уку-язу әйберләре) узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда 8,7 һәм 6,5 процентка кыйммәтләнгән.

Уртачадан бераз өстә

Хезмәт хакы күләме Россия буенча уртача күрсәткечтән югарырак булган төбәкләр исемнәре билгеле. «РИА-Новости» бу җәһәттән рейтинг төзеп бастырган. Шулай итеп, иң бай төбәкләргә Ямал-Ненец автономияле округы (биредә яшәүчеләрнең 71,9 проценты уртача күрсәткечтән зуррак хезмәт хакы алып эшли), Чукотка (59,3%), Ненец автономияле округы (58,5%), Ханты-Манси автономияле округы (56,7%) һәм Магадан өлкәсе (55,6%) кергән. Ә менә Иваново өлкәсе (9,7%), Чечня (10,1%), Калмыкия (11,4%), Алтай крае (11,5%) һәм Ингушетия (12%) иң начар нәтиҗәләр күрсәткән.

Татарстан әлеге рейтингта 23 нче урында урнашкан. Бездә уртача күрсәткечтән зуррак эш хакы алучы хезмәткәрләр өлеше 28,8% тәшкил иткән.

Соңгы елда илдә уртача хезмәт хакы 52 мең сум булган. Тулаем алганда, Россиядә хезмәткәрләрнең 31 проценты – бу суммадан күбрәк, 9,3 проценты аннан ике тапкыр артыграк акча алып эшли икән.

COVID-19

Көтелгән кунак

СОҢГЫ АТНАДА ТАТАРСТАНДА КОРОНАВИРУС БЕЛӘН АВЫРУЧЫЛАР 30 ПРОЦЕНТКА АРТКАН

Биткә битлек эләргә. Роспотребнадзор белгечләре җәмәгать урыннарында һәм транспорт чараларында битлек кияргә киңәш итте. Коронавирус белән чирләүчеләр саны арту аркасында, саклык чаралары турында яңадан искә төшерергә кирәк.

Искәртеп үтик: Роспотребнадзор 16 августта ук коронавирус белән авыручылар саны 100 мең кешегә 50 очрактан арткан төбәкләрдә битлек киеп йөрергә киңәш итте. Россиядә теркәлгән барлык очракларның 49 проценты диярлек Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Мәскәү өлкәсенә туры килә.

Соңгы атнада Татарстанда да авыручыларның кисәк кенә артуын күзәтергә мөмкин. Әмма статистикага ышансаң, атнадан артык инде чирдән үлүчеләр юк.

– Бу – көтелгән үсеш иде. Ул вирусның мутацияләнүе аркасында килеп чыкты. Инфекция тиз тарала, авыручылар саны да артачак, – диде Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы Марина Патяшина.

Июль ае белән чагыштырганда, Татарстанда чирлеләр саны 2 тапкыр арткан. Белгечләр «омикрон» штаммының өстенлек итүен әйтә.

– Шулай да медицина хезмәткәрләре үз эшен башкарырга өлгерә, хастаханәләргә өстәмә ятаклар кирәк түгел, – диде бу уңайдан Марина Патяшина.

Хәтерегездә булса, республикада битлек кию режимын 6 июньдә туктатканнар иде. Моны коронавирус белән чирләүчеләр саны киму белән аңлаттылар. Ул чакта тәүлеклек авыручылар күрсәткече 3,5 проценттан 0,08 процентка калган иде.

Россиядә авыруның иң югары ноктасы кабат көзгә туры киләчәк. Вирусолог Анатолий Альтштейн фикеренчә, август азагы – сентябрь башы шундый «күчтәнәч» әзерли. Белгечләр башка илләрдән алган фәнни мәгълүматлар нигезендә мондый нәтиҗәгә килгән. «Россиядә коронавирус белән авыручыларның тәүлеклек саны 50, 60, 70 меңгә җитәргә мөмкин, әмма шуннан да артыграк булуы икеле», – ди вирусолог.

САН

22 августка караган мәгълүмат буенча, соңгы тәүлектә Россиядә коронавирус инфекциясе йоктыруның 33061 очрагы ачыкланган. 1704 кешене хастаханәгә салганнар, 22 меңнән артык кеше дәваланып чыккан. Чирдән 57 кеше үлгән. Татарстандагы вазгыятькә килгәндә, инфекция йоктыруның 126 очрагы расланган. 54 кеше хастаханәгә озатылган. Үлүчеләр юк.

Сүзгә-сүз

Лилия БАСАНОВА, ДРКБ баш табибының медицина буенча урынбасары:

Табибларга һәрвакыт әйтәм: теләсә кайсы әни белән уртак тел таба белергә кирәк. Аларны безнең бер яклы булуыбызга ышандыру мөһим. Баланың хәлен җиңеләйтү, аны мөмкин булганча дәвалау – әтиәниләр белән уртак бурычыбыз. Әниләргә әнә шуны җиткерә алсаң, бик яхшы.

(«Реальное время»дан)

ТАТАРСТАНДА УРЫП-ҖЫЮ

22 августка булган мәгълүматларга караганда, республика кырларыннан 3,2 миллион тонна уңыш җыеп алынган. Урып-җыю эшләре 836585 гектарда башкарылган. Уртача уңыш гектарыннан 38,1 центнерны тәшкил итә.

ИҢ ЗУР УҢЫШ КАЙДА ЧЫГА?

Район	Суктырып алынган (т)	Уртача уңыш (ц/га)
Тәтеш	161238	50,4
Буа	143260	39,6
Минзәлә	134493	49,1
Яңа Чишмә	122861	46,5
Спас	120656	40,2
Актаныш	117604	39,2
Мөслим	113398	38,4
Чистай	111274	38,4
Сарман	108582	41,6
Нурлат	105082	38,0

Көз җылы килә

Россиядә октябрьнең беренче декадасына кадәр җылы булырга мөмкин. Гидрометеоүзәк җитәкчесе Роман Вильфанд шулай дип белдергән. «Хәзерге вакытта һава температурасы тел-теш тидергесез дәрәҗәдә әйбәт. Кара диңгезнең көнчыгышында су температурасы +25…+26, Сочи һәм Анапада +28 градус тәшкил итә. Экватордагы су температурасы бу. Бездә бик сирәк күренеш. Калининград өлкәсендә дә суның температурасы +24 градус. Океан суы бик нык җылынган, сентябрьдә җылылык судан һавага күчәчәк», – дигән Вильфанд ТАСС хәбәрчесенә.

Шул ук вакытта ул бәрхет сезонының, гадәттә, сентябрь ахырына кадәр дәвам итүен билгеләп үткән.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БАЛИ САММИТЫ НИ ВӘГЪДӘ ИТӘ?

«Зур егермелек»нең (G-20) Индонезиядәге очрашуына бәйле вакыйгалар соңгы көннәрдә дөнья сәясәтенең төп мәсьәләләренең берсенә әверелеп килә. Икътисадлары иң зур булган илләрнең лидерлары сәясәтнең шахмат тактасында, рокировкалар һәм ат йөрешләре ясап, үз илләренең позициясен яхшыртырга тырыша.

Әле саммитка кадәр байтак вакыт булса да, бәхәсләр кыза, сөйләшүләрнең алшартларын әзерләү процессы күптән башланды инде. Күп кенә Көнбатыш илләренең лидерлары Балига Путинның килүенә каршы чыкты, аның визитын әхлаксызлык дип бәяләргә теләүчеләр булды. Әмма Индонезия Президенты Джоко Видодо очрашуда Россия һәм Кытай лидерларының булачагын әйтә. Әле ноябрьгә кадәр байтак вакыт бар, 3 ай эчендә безнең тиз үзгәрүчән дөньябызда әллә никадәр үзгәрешләр булу ихтимал. Тик шулай да очрашуның табын хуҗасы, Көнбатыш басымына каршы торып, өстәл янына лидерларны тулы составта җыюны яклый. Үткән атнада Вашингтон «Балида Путин булса, Зеленский да килсен» дигән шарт куйды. Куркыныч рәвештә зурга әйләнеп баручы конфликт лидерларын күзгә-күз очраштырмакчылар. Ике лидер очрашып, компромисслар турында килешә алса, бик яхшы булыр иде, әлбәттә.

Бали уртавының көньягындагы Нуса-Дуадагы затлы кунакханәләр һәм пляжлар геосәясәтнең башка юнәлешләрендә дә зур маневрлар вәгъдә итәләр. Кытай лидеры Си Цзиньпин белән АКШ Президенты Байденның очрашуы көтелә. Безгә мәгълүм булганча, яклар Тайвань тирәсендәге киеренкелекне йомшартырга телиләр. Кытайның төп тышкы сәүдә партнеры – АКШ, ике ил арасындагы товар әйләнеше 755,7 миллиард доллар тәшкил итә. Чагыштырыгыз: Россия – Кытай сәүдәсе 146,9 миллиард доллар гына. Бу хәтта Вьетнам – Кытай, Бразилия – Кытай, Малайзия – Кытай бәйләнешләренә караганда да күпкә кимрәк. Хәтта Кытай белән салкын сугыш хәлендәге Австралия дә чин базарында 232,1 миллиард долларлык товар алмаша. Димәк, АКШ – Кытай мөнәсәбәтләрендә уртак тел табылса, Пекинга Мәскәү белән җылы мөнәсәбәтләрне бераз туңдыру артык катлаулы дип әйтеп булмый. Вашингтон чиннарга бу юнәлештә басым ясарга тырыша, бу – сер түгел. АКШ белән араны өзү Европа белән дә талашу, японнар белән дә тәмам бозылышуга тиң. Кытай – Япония мөнәсәбәтләре исә 371,4 миллиард доллар тора. 19 август көнне япон премьеры Кисиданың да Кытай җитәкчесе белән уртак табында утырырга теләве мәгълүм булды. Ике ил арасында мөнәсәбәтләр бик киеренке. Японнар ул киеренкелекне йомшартырга тели. Пекин да каршы түгел икән. Үткән атнада гына японнарның Милли куркынычсызлык советы җитәкчесе Акиба Пекинда Ян Цзечи – Кытай Компартиясе Үзәк Комитеты Политбюросы әгъзасы, ҮКның тышкы эшләр комиссиясе җитәкчесе белән җиде сәгатьлек сөйләшүләр алып барган. Безгә шул мәгълүм булды: японнар АКШ белән Кытай якынаеп, Пекин белән дошманлыкта ялгыз калудан да куркалар икән. Димәк, Бали саммиты Азия гигантларының дус яшәү турында килешүләренә китерергә ихтимал. Ә бу Россиянең изоляциясен көчәйтергә мөмкин. Сәясәттә, билгеле, бик катлаулы су асты агымнары бар. Зур корабларны бөтереп суырып алып кереп китүче чоңгыллар да хасил була ала. Индонезиядәге G-20 саммиты бүген үк зур интригалар формалаштыра һәм игътибар үзәгендә тора.

Россиядә

БӨЛӘБЕЗМЕ, ТЕРЕЛӘБЕЗМЕ?

Россиялеләрнең матди хәленә бәйле яңалыклар бүген эчке сәясәтнең төп темасы булып тора. Росстат инфляцияне исәпләүнең методикасын дүртенче тапкыр яңага алыштырды. Яңача исәпләгәч, бәяләр күтәрелеше алай ук зур булып күренмәячәк.

Медицинада плацебо эффекты дигән нәрсә бар бит әле: ышансаң, акбурдан ясалган төймә дә дәвага әверелә ала. Безне икътисади төшенкелектән дә шул ысул белән дәваламакчылар. Икътисади үсеш министрлыгы да Үзәк банк артыннан илнең икътисади хәленә бәйле фаразларны яхшыртты. Май аенда министрлыкта, эчке тулай продуктның кимүе 7,8 процент булыр, дип фаразлаганнар иде. Хәзер, яңартылган фараз буенча, түбәнгә тәгәрәү 4,2 процент кына булачак дип көтелә. Дөрес, үсеш стратегиясен билгеләүче рәсми белгечләр түбәнәюнең 2023 елда элек фаразлаганга караганда көчлерәк буласын әйтәләр. Максим Решетников конторасындагылар безне, кризис җиңелчә салкын тиюгә охшаган бер чир генә булыр, үтәр дә китәр, дип юаталар.

Заманында Михаил Горбачевның икътисад буенча киңәшчесе булып торган, Россия Фәннәр академиясе академигы Абел Агенбегян вазгыятькә башкачарак карый. Россия матбугатына соңгы көннәрдә биргән интервьюларында ул Россия икътисадының 1990 нчы еллар ахырыннан соң кичергән барлык кризисларга караганда да тирәнрәк кризиска батып баруын белдерә. Аның фикеренчә, икътисади түбәнәю 1998 елгы дефолт чорындагыдан ике тапкыр, 2014–2016 еллар болганчыклыгыннан өч тапкыр куәтлерәк булачак. Сәнәгать 10 процент югалтачак, ә фәкыйрьлек дәрәҗәсе СССР таркалуның беренче елларындагы чамалырак булачак.

Академик эшсезлек дәрәҗәсе (яшерен эшсезлекне дә кертеп) ике тапкыр артачак дип саный ул. Россиялеләргә берничә ел дәвамында акчаны бик нык кысып тотарга туры киләчәк. Хәзер халыкның 18 проценты фәкыйрьлек чигендә яши, ди ул. Болар, гадәти «Пятерочка»га кереп, үзләре теләгән ризыкны ала алмыйлар, көн саен ит ашау эләкми. Өченче-дүртенче кварталларда кризис үзенең югары ноктасына җиткәч, аларның саны, 1,5 тапкыр артып, 25–30 процент булачак, ягъни 43 миллион тирәсе кеше фәкыйрьлек зонасында яшәүгә күчәчәк.

Вазгыятьне төзәтү өчен, Агенбегян яңадан бишьеллык планлаштыруга күчәргә чакыра. Дөньядагы икенче державага әйләнгәнче, японнар алты «бишьеллык» аша үттеләр, ди. Һиндстанның һәм Төркиянең дә «бишьеллык»лар баскычында югары үрләүләрен дәлилли. Дөрес, сүз совет бишьеллыклары турында бармый. Бизнес белән киңәшеп, алдагы елларга офыклар билгеләү хакында гына. Академикның бу хыялын федераль хөкүмәт тормышка ашырырга җыена да инде. Сәнәгатьнең дүрт тармагы: авиация һәм корабльләр төзелеше, дарулар җитештерү, җитештерү җиһазлары ясау планлы режимга күчәр дип көтелә.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Үз көченә таяныр чак

Пирчәткә, катализаторларны үзебездә җитештерү, ясалма интеллект юнәлешенә зур өметләр баглау… Кичә Хөкүмәт йортында узган киңәшмәләрдә бүгенге шартларда икътисадта куелган максат-бурычлар хакында сөйләштеләр. Утырышларда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Әйтик, «Сибур»ның «Үсеш һәм инновацияләр» юнәлеше директоры Дарья Борисова авиация һәм нефть-газ сәнәгате өчен кирәкле махсус полимерлар, медицина пирчәткәләре белән полиолефин һәм пиролиз өчен катализаторлар җитештерү ниятләре турында сөйләде. «Җитештерүгә кирәкле күпсанлы компонентларны безнең белән дустанә булган илләрдә табарга мөмкин. Әмма аларның кайберләрен, әйтик, шул ук катализаторларны табу кыен. Аларның булмавы аркасында, җитештерү тукталырга мөмкин», – ди белгеч.

Дарья Борисова совет чорында «Казаноргсинтез» заводында катализатор фабрикасы эшләвен дә искә алды. Аның базасында бүген дә катализаторлар җитештереп булыр иде, дип саный ул. «Пандемиягә кадәр Россиядә латекс һәм пирчәткәләр дә җитештерелми иде. Алар барысы да Азиядән кертелде. «Сибур» Красноярскида бу юнәлештә пилот проекты башлап җибәрде. Аны Татарстанда да тормышка ашырсак, яхшы булыр иде», – диде белгеч. Рөстәм Миңнеханов Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән «Татнефтехиминвест-холдинг»ка әлеге проектлардан читтә калмаска кушты.

Президент «ТЭМПО» машина төзелеш холдингына да импорт алмаштыру кысасында эшчәнлек юнәлешләрен киңәйтергә киңәш итте. Хәзерге вакытта оешма «КамАЗ» машиналары өчен моторлар, транспорт өчен электр җиһазлары, махсус техника, пыяла торбалар җитештерү белән шөгыльләнә.

КамАЗның металл булмаган эшләнмәләр һәм материаллар бюросы башлыгы Александр Летуновский сүзләренә караганда, бүген «КамАЗ» машиналары өчен резин-техник эшләнмәләр җитештерү юнәлешендә дә кыенлыклар бар. Бүген җылыткычлар эшләп чыгаруның яңа ысулларын үзләштерергә, инженерлар әзерләү өчен, махсус фәнни институтлар булдырырга кирәк, дигән фикердә ул.

Рөстәм Миңнеханов, чикләүләр аркасында, КамАЗның кайбер төр продукцияне җитештерә алмавын искәртте. Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән «Татнефтехиминвест-холдинг» оешмаларына яңа партнерлар җәлеп итәргә кирәклеген дә ассызыклады. «Моннан тыш кече һәм урта эшмәкәрләргә дә ярдәм итәргә кирәк», – диде Президент.

Утырышта тагын берничә кызыклы проект тәкъдим ителә. Аерым алганда, Татарстанда яңа тарифларны сынап карарга мөмкинлек бирүче махсус энергетик зона булдырырга тәкъдим итәләр. «Иннополис» шәһәрчегендә яңа IT-платформа да пәйда булырга мөмкин. Ул яңа продуктларны сәнәгатьтә сынау вакытын киметер дип көтелә. «Иннополистан ясалма интеллект тармагында зур нәтиҗәләр көтәбез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН: «БУ МӘКТӘПНЕ ОНЫТМЫЙМ»

tatarstan.ru

«Татнефть» җәмгыятенең төп нефть-газ чыгару идарәләреннән берсе – «Әлмәтнефть»кә 70 ел тулды. Бу уңайдан нефтьчеләр башкаласында тантаналы чара узды.

Бәйрәм уңаеннан идарә хезмәткәрләрен һәм ветераннарын республика җитәкчелеге исеменнән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

Ул үзенең чыгышында Президент Рөстәм Миңнеханов исеменнән котлау телеграммасын укып үтте. «Бүген «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсе – «кара алтын» чыгаруның иң зур үзәге һәм нефть-газ тармагында эшләүнең иң алдынгы ысулларын үзләштерү урыны, – диелә котлауда. – Предприятиене үстерүнең республика көньяк-көнчыгышында яшәүчеләр тормышын яхшы якка үзгәртүе: юллар, йортлар, социаль һәм мәгариф учреждениеләре төзү, ишегалларын, парк-скверларны төзекләндерү мөһим. Әлеге бәйрәм яңа хезмәт үрләре өчен яңа этәргеч ноктасына әйләнсен!»

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, «Әлмәтнефть» 70 ел эчендә илебезнең нефть тармагын үстерүгә үзеннән саллы өлеш керткән, сугыштан соң икътисадны торгызуга, сәнәгатьне яңартуда бик зур ярдәм иткән. «Нефтьчеләр Татарстанда ел саен 32–35 миллион тоннага якын «кара алтын» чыгара. Шуның 80 процентын – «Татнефть» хезмәткәрләре. Сәнәгатьнең мөһим тармагы гына түгел, икътисади мөмкинлекләрне төп булдыручы да ул. Татарстан бюджетына керемнәрнең өчтән бер өлешенә кадәрен шушы компания кертә», – диде парламент башлыгы.

Нефтьчеләрнең һәр буынына ниндидер авырлыклар аша узарга туры килә. «Замана үзгәрә, хәзер нефтьне җиңел генә табып булмый. Башка сәбәпләр дә «кара алтын» чыгару һәм эшкәртүгә җитди йогынты ясый, – дип билгеләп үтте ул. – Шуңа күрә профессиональлек, булдыклылык, киләчәкне күздә тотып эшләү кирәк. «Татнефть», бүгенге генераль директоры Наил Мәганов җитәкчелегендә яңа кыенлыклардан чыгып, катлаулы бурычларны оста хәл итеп килә».

Дәүләт Советы Рәисе сүзләренә караганда, нефть чыгару эшенең барлык нечкәлекләрен белүче оста җитәкчеләрдән, көчле, профессиональ коллективтан башка гына мондый нәтиҗәләргә ирешеп булмый.

Парламент башлыгы җиде дистә ел эчендә идарәне җитәкләгән барлык җитәкчеләрне исемләп санап үтте, хезмәт династияләрен искә төшерде. Шулай ук туып-үскән шәһәрендәге тәүге эш адымнары турындагы хатирәләрен яңартты. «Әтием «Әлмәтнефть»тә эшләде, үземә дә армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң идарәдә эшләргә насыйп булды. Җитештерүне автоматлаштыру цехында контроль-үлчәү приборлары һәм автоматика слесаре сыйфатында хезмәт юлын башлап җибәрдем, – дип сөйләде ул. – Комсомолда, башкарма комитет, шәһәр советы, партия шәһәр комитетында төрле вазыйфаларда эшләгәндә һәм бүген дә кайчандыр «Әлмәтнефть»тә хезмәт чыныгуы алучылар белән хезмәттәшлек итәм. Бу мәктәпне әлегәчә онытмыйм!»

КИҢӘШМИЧӘ БУЛМЫЙ

Казанда Россия Иҗтимагый палатасының «Сообщество» форумы башлана. Идел буе федераль округының коммерцияле булмаган оешма вәкилләре, волонтерлар һәм социаль юнәлештә эшләүче башка активистлар бер мәйданчыкта очрашып, көнүзәк мәсьәләләр, үзләрен борчыган сораулар турында фикер алышачак. 24–25 август көннәрендә буласы форумның әһәмияте, анда күтәреләчәк мәсьәләләр хакында Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә ВӘЛИЕВА белән сөйләштек.

:: Зилә Рәхимҗановна, Казанга кемнәр җыела һәмниләр хакында фикер алыша?

– «Сообщество» форумы – Россия Иҗтимагый палатасының традицион чарасы. Быел Идел буе федераль округына керә торган төбәкләр Казанга киләчәк. Ләкин безнең кунакларның географиясе күпкә киңрәк, 75 төбәктән катнашучылар теркәлде. Экспертлар, коммерцияле булмаган һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре, активистлар, гомумән, җәмгыятьтә барган процессларга битараф булмаучылар, хакимият органнары һәм бизнес вәкилләре – барысы бер урында очрашачак. Бу үзенә күрә зур көч тупланган урын булыр дип уйлыйм. Казандагы форумның төп темасы – «Россия: мәдәниятләрнең күптөрлелеге, гражданнарның бердәмлеге». Идел буе төбәкләрендә төрледән-төрле милләт вәкилләре бердәм булып яши. Татарстан да бу яктан башкаларга үрнәк булып тора. Миңа калса, форумның темасы безгә аеруча туры килә. Моннан тыш, әлеге җыен кысасында махсус чаралар да узачак.

:: Бүгенге вазгыятьтә бердәмлекнең ни дәрәҗәдә көн кадагында булганын әйтеп тә торасы юк…

– Глобальләшү чорында, халыклар арасындагы татулыкны күз карасыдай сакларга кирәк вакытта әлеге темага сөйләшүнең әһәмияте гаять зур. Тормыш үзгәрә, безгә һаман саен яңа проблемалар, замана таләпләре белән күзгә-күз очрашырга туры килә. Аларны бергә хәл итәргә кирәк. Чөнки барыбыз да бер үк максат – рухи мирасыбызны саклау, үстерү һәм киләчәк буынга тапшыру хакына тырышабыз. Форум кысасындагы фикер алышулар, тәҗрибә уртаклашулар нәтиҗәсез калмас, минемчә.

Билгеле, бу әле – төп тема гына. Гомумән алганда, форум кысасында 45ләп мәйданчыкта фикер алышачаклар. Демография мәсьәләләре, белем бирү, халыкның көнкүреш проблемалары, мәдәният, яшьләрне борчыган сораулар – гомумән, форумда күтәреләчәк темалар яшәешебезнең төрле якларын колачлый һәм бик күпләрне борчый. Дөнья «усалланды». Кешеләр сөйләшеп аңлашуның әһәмиятен оныта кебек. Шуңа күрә фикер алышу, уртага салып сөйләшү форматындагы очрашуларның әһәмияте һәм кыйммәте елдан-ел арта.

:: Форумны уздыру урыны итеп, ни өчен нәкъ менә Татарстан башкаласы сайланды?

– Башка төбәкләрне Татарстанның тәҗрибәсе кызыксындыруы инде яңалык түгел. Шулай да, әлеге форумны уздыру урыны ниндидер махсус конкурс нигезендә сайланмады. Ул ел саен төрле шәһәрдә уздырыла. Әйтик, узган ел Идел буе федераль округы төбәкләре Саранскида очрашты. Быел менә Казанда. Форум кампаниясе ноябрьдә Мәскәүдә узачак йомгаклау чарасы белән тәмамлана.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

БАЛЫКЛЫГА – МӘКТӘП, ЧЕРНЫШЕВКАГА – БАКЧА

Яңа уку елын көткәндә

Түбәләр ябылган, идәннәр җәелгән. Быел Татарстанда мәгариф оешмаларын төзекләндерү өчен 7,5 миллиард сум акча бүлеп бирелгән. 1 сентябрьдә республикада 9 яңа мәктәп ачылачак. Шуларның икесе – Әлмәт һәм Түбән Камада төзелүче «Адымнар» күптелле мәктәпләре. Белем йортлары укучыларын каршыларга әзерме?

Соңгы биш елда республикада 41 мәктәп төзелгән. Быел ел дәвамында тагын 11е кулланышка тапшырылачак. Яңа мәктәпле булу бәхете тигән районнар арасында Әлмәт тә бар. Монда быел 1 нче сыйныфка 3 меңләп бала барачак. Бу сан узган елгы белән бер чама.

– Бездә «Адымнар» күптелле мәктәбе ачыла. Мәктәп әзер, 800ләп укучы гариза бирде инде. «Татнефть» ярдәме белән сәнгать мәктәбе яңа урынга күчә. Бик шәп бина булачак бу. Быел федераль программа буенча ярты миллиард сумга мәктәпләр төзекләндерелде, ашханәләр яңартылды. Кванториум төзелә, димәк, быел тагын бер инженерлык үзәге булачак, – диде безгә Әлмәт районы башлыгы Тимур Нагуманов, яңалыклар белән уртаклашып.

Аннан ябылган белем йортлары турында да сораштык. «Андый мәктәпләр юк, аларны япмыйбыз. Кайчак кыскартырга туры килә анысы. Әйтик, 9 нчы сыйныфтан соң укучылар җыелмаса… Быел андый сорау тумады», – диде башлык.

Тукай районында быел 1 нче сыйныфка 528 бала килер дип көтелә. Бу сан узган елгыдан бик аерылмый Әмма шунысы сөенечле: ел саен укучылар саны 300гә арта икән. Район мәгариф бүлеге башлыгы Әлфәт Сабиров моның сәбәбен шәһәрдән күченеп килүчеләргә бәйләп аңлатты.

– Бездә укучылар саны арта. Былтыр уку елын 4001 укучы белән башласак, быел аларның саны 4335 булачак. Шәһәр яны районы булгач, Чаллыдан күченеп кайтучылар күп. Елга 300 бала арта, бу – бер мәктәп дигән сүз. Быел Шилнәбаш мәктәбе төзелә, аны декабрьдә ачачакбыз. Бала саны арткач, сыймыйлар. Новотроицк авылындагы бакча, Князь мәктәбе төзекләндерелә. Районда ябылган мәктәпләр юк, кыскарту хакында уйлаган да юк. Балалар саны арта бит, ничек ябасың? – ди Әлфәт Сабиров.

Районда укучыларның якынча 10 проценты икенче сменада укый. Быел Түбән Суыксу мәктәбендә шундый тәртип кертелә. Иминлек мәсьәләсенә килгәндә, барлык бакча-мәктәпләр дә шәхси сак хезмәткәрләре белән тәэмин ителгән. «Узган ел хөкүмәт акча бүлеп бирде, быел да бу эш дәвам иттереләчәк. Әти-әниләрдән бер тиен дә җыймыйбыз», – диде Әлфәт Сабиров.

Теләче районы башлыгы Нәҗип Хаҗипов белдергәнчә, быел районда ябылган мәктәпләр юк. «Кызганыч, кечкенә авылларда сабыйлар бик аз туа. Кыскартырга туры киләчәк. Районда быел 1 нче сыйныфка 100дән артык бала барса, шуның 84е – район үзәгендә, – диде ул. – Мәктәпләребез балаларны каршыларга әзер. Быел «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» акциясендә райондашлар бик актив катнашты. Теләк белдерүчеләр дә күп, җыйган әйберләр дә мулдан булды. Укытучылар җитә. Быел 11 яңа укытучы киләчәк».

Балтач районы мәгариф идарәсе башлыгы Ренат Мөхәрләмов, районга яшь укытучылар бик кирәк, ди. Быел өч физкультура укытучысы кайткан икән. Тик физика, математика, рус һәм инглиз теле укытучыларына кытлык бар. «Ир укытучылар да аз түгел, әмма яшьләр генә кайтырга атлыгып тормый. Киләчәктә «Мобиль укытучы» программасын булдыру нияте дә бар. Машина биргән очракта, укытучылар башка мәктәпләргә барып укытырга әзер», – диде Ренат Мөхәрләмов.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яңа уку елында ачылачак мәктәп, бакчалар исемлеге

1. Яшел Үзән районында «Мирный» бистәсендә яңа мәктәп (1224 урынга исәпләнгән)
2. Түбән Камада «Адымнар» күптелле мәктәбе (1224)
3. Түбән Камада мәктәп (950)
4. Түбән Камада бакча (320)
5. Әлмәттә «Адымнар» күптелле мәктәбе (1224)
6. Чаллы мәктәп (1501)
7. Биектауда мәктәп (500)
8. Биектауның Алат авылында мәктәп (80) һәм бакча (20)
9. Биектау районының Чернышевка авылында бакча (140)
10. Саба районының Байлар Сабасы бистәсендә мәктәп (500)
11. Кукмара районы Балыклы авылында мәктәп (15)

Сәрия МИФТАХОВА

АЗАТ ВӘЛИЕВ:

«ӘГЕРҖЕНЕҢ ҮСЕШ МӨМКИНЛЕГЕ ЗУР»

Әгерҗе – башкаладан иң ерак урнашкан районнарның берсе. Шунысы кызык: Әгерҗенең Татарстанның башка районнары белән коры җирдә чикләре юк. Ягъни ул Менделеевск, Тукай һәм Минзәлә районнары белән бары тик Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча чиктәш. Коры җирдә исә Әгерҗе Удмуртиянең алты районы белән күрше. Менә шундый үзенчәлекле район бүген ничек яшәп ята? Ике ел элек башлык булып билгеләнгән Азат ВӘЛИЕВ белән Әгерҗенең өмет һәм ниятләре турында сөйләштек.

agryz-rt.ru

Әгерҗе бүген

Безнең район бик матур. Ул урманнарга, су һәм биоресурсларга бик бай. Безнең районда аю, поши, селәүсен күрү – гадәти хәл. Хәтта Әгерҗе урамнарында пошиларга кадәр очратырга мөмкин. Башка урман җәнлекләре турында әйтеп тә тормыйм инде. Әле үзем дә күптән түгел генә урман кунагын очраттым. Кадрәк авылы янында каршыбыздан бик зур аю йөгереп узды.

Район милләтләр буенча да үзенчәлекле. Монда татарлар, удмуртлар, марилар, руслар дус яши. Халыкның 98 проценты марилар гына булган авыллар бар. Һәр милләтнең – үз мәдәнияте. Аларны саклап калырга кирәк.

Моннан тыш, Әгерҗе – тимер юлы булу белән данлыклы. Биредә эре тимер юллар кисешә, бик күп пассажирлар агымы бар. Әгерҗе станциясе Россиянең узеллы станцияләре исемлегенә керә. Ягъни гадәти станция генә түгел. Безнең Куйбышев юлына, Төньяк юнәлешкә чыгу мөмкинлегебез бар. Шуңа күрә районның зур тимер юл кластеры бар. Халыкның өчтән бере шушы тармакта эшли. Районга килгәч, Президент Рөстәм Миңнеханов тарафыннан куелган беренче бурыч икътисадка юнәлдерелгән зур проектлар булдыру иде. Кызганыч ки, берничә ел дәвамында район социаль-икътисади үсеш буенча артта бара. Мин үзем – һөнәрем буенча икътисадчы. Һәм алга таба зур адым ясар өчен, зур проектлар кирәклеген бик яхшы аңлыйм. Монда килгәч, «Нинди проектлар башлап булыр икән?» – дип уйлана башладым. Ә инвесторлар белән эшләү бер дә җиңел түгел. Башта районлагы көчле, зур оешмалар турында уйладым. Ләкин алай гына алга китеп булмасын аңлагач, инвесторларны читтән эзли башладык. Чөнки районда андый көчле инвесторлар юк. Әйе, кечкенә проектлар бар, алар да бик мөһим. Тик зур үсеш өчен безгә барыбер зур проектлар кирәк.

Һәм иртәгә

Әлеге проектлар буенча зур эшләр башланды да инде. Беренчедән, иң зур проектыбыз – логистик сәнәгать паркы. Инвестор булырлык кеше дә табылды. Ул 169 гектар пай җирләрен сатып алды. Алар инде әлеге проектның мастер-планын да эшләде. Әгерҗе районы әлегә үзенең логистик мөмкинлекләрен тормышка ашырмады. Ә алар бик зур. Мондый мөмкинлек берничә районда гына бар. Бездә бит тимер юл гына түгел, янәшәдә генә М7 федераль трассасы уза. Анализ ясагач, Әгерҗе яныннан бер сәгатькә 300 фура йөрүе, тәүлегенә 10 меңнән артык вагон узуы ачыкланды. Йөк башта Мәскәүгә яки Питерга бара. Анда контейнерлар алына, һәм фуралар әлеге товарның бер өлешен Идел буе зонасына алып китә. Әгәр монда логистик үзәк барлыкка килсә, чит илдән килә торган контейнерлар биредә туктап, бушатылса, вакыт һәм акча янга калыр иде. Бу – әлбәттә, яңа эш урыннары дигән сүз. Аның әһәмияте район гына түгел, Татарстан өчен дә зур. Әйе, без Казаннан ерак, аның каравы Удмуртиягә, Башкортстанга, Киров өлкәсенә якын. Киләчәктә әлеге парк янында нәрсәдер җитештерергә мөмкин булыр иде. Ягъни үзебезгә балык тотар өчен кармак булыр иде. Әлегә каршылыклар зур, билгеле. Ләкин әгәр шушы проектны ахырга кадәр алып барып җиткерә алам икән, гомерем юкка узмаган дип санарга мөмкин.

Икенчесе – авыл хуҗалыгы. Анда да мөмкинлекләр зур. Безнең авыл хуҗалыгында файдаланмый торган җирләр күп. Күптәннән урман каплап киткән җирләр бар. Менә аларны да авыл хуҗалыгына кертеп җибәрәсе иде. Районда сөт күләме буенча да уңай динамика бар. Быел без тәүлегенә 50 тоннадан артык сөт сатып ала башладык. Ике-өч ел элек әлеге күрсәткечләр буенча республика рейтингында ахыргы урында булсак, хәзер беренче егермелеккә кердек. Шуңа күрә бу юнәлештә дә үсеш буенча өметләребез бар. Авыл хуҗалыгыннан башка берничек тә булмый. Бу – беренче чиратта, авылны саклап калу дигән сүз. Һәм ул бик мөһим. Ләкин үсемлекчелек белән генә авылны саклап калып булмый. Шуңа күрә терлекчелеккә дә зур игътибар бирергә кирәк.

Өченче юнәлеш – эчке туризм. Зур туристик комплекс булдырырга бөтен мөмкинлегебез бар. Бөтен район буйлап Иж елгасы ага. Кама акваториясе, бай урманнарыбыз бар. 100 эш урыны бирүче консервлау заводы төзергә планлаштырабыз. Әлеге вакытта Кама яр буенда кунакханә төзибез.

Моннан тыш, һөнәрчелекне үстерергә телибез. Иж-Бубый авылында сәламәтлек өчен бик файдалы минераль су чыга. Әгәр аның чыганагы Кама яр буендагы Красный Бор авылы тирәсендә дә табылса, заманча сәламәтләндерү үзәге төзеп булыр иде. Районда бер генә сәнәгать теплицасы да, су күп булуга карамастан, бер генә ял итү базасы да, яхшы пляжлар да юк. Бу юнәлештә дә эшләргә телибез. Районның шушы кадәр матурлыгын тулысынча файдаланырга кирәк дип саныйм. Кызганыч, районда эре эшкәртү объектлары юк. Ашлык та, сөт тә, урман да читкә китә. Шуңа күрә әлеге юнәлешләр буенча инвесторларны бөтен Россия буйлап эзлибез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Язылганга кире кайтып

«БЕЗ ХӘЗЕР ЯҢА ӨЙДӘ ЯШИБЕЗ БИТ»

Балтачтагы даруханәгә керсәм, миннән алда гына күптәнге танышым Рәйсә дарулар ала. Бүлдермичә көтеп тордым да хәлләрен сораштым. Көтмәгәндә очрашуга икебез дә сөендек шикелле. Рәйсә – Балтач районындагы Әтнә авылы кызы, бик күп язмаларымның герое. Атауныкылар – ятим Гатауллиннар турында инде күп яздым. Район газетасында эшләгәндә, 1995 елда ук башлаган әлеге теманы, еллар үткәч тә, читкә куеп булмады шул. Язмышлары бигрәк ачы, онытмыра торган түгел.

vk.com/фото бизгә өчен бирелә

«Ватаным Татарстан»ны даими укучылар хәтерли торгандыр: әтиләре үлгәч, сукыр һәм параличланган әни тәрбиясендә калган берсеннән-берсе кечкенә дүрт сабый… Ачлыкны да, юклыкны да, башкасын да татыган, бер-бер артлы әтиләрен, әниләрен, бабайларын, әтиләренең үзләренә ярдәм итәргә дип кайткан сеңлесе Гөлниса апаларын, Якуб җизнәләрен соңгы юлга озаткан һәм… кырыс язмыш каршында ни ризыкка, ни киемгә, ни сәламәтлеккә туймас мохтаҗ булып, япа-ялгыз калган бу балалар турында без инде берничә ел дәвамында кайта-кайта яздык.

Аларның берсендә мин: «Гыйбрәт өчен дип язылган язмаларның бөтенләй башка борылыш аласын әле ул чакта беребез дә уйламаган идек», – дигәнмен һәм, безне ишетеп, бу ятимнәргә ярдәм итәргә алынган, аларга күп еллар дәвамында терәк-таяныч булган чит-ятлар турында сөенеп, сокланып язганмын. Районныкылар гына түгел, Әлмәттән кадәр елына әллә ничәләр, машинасына кием-салым, мебель, ашамлыклар төяп килгән, бу балаларга әйтеп-санап бетергесез күп яхшылык-изгелекләр эшләгән, аларның да кешечә мөнәсәбәткә бик лаек икәнлекләрен исбатлый алган пенсия яшендәге Мирсәет абый Сәйфиев… Үзебезнең районның Арбор авылында яшәүче, безнең язмаларны елый-елый укып, ике дә уйламыйча, төпчек уллары Камилне шул ятим кызларның берсе Нурсинә белән кавыштырган Рауза һәм Шамил Шакировлар… Балаларны даими эшле дә, ашлы да иткән, бик күп матди ярдәм күрсәткән (һәм бүгенгә кадәр алар белән даими кызыксынып, ярдәм итеп торучы) хуҗалык рәисе Рәкыйп Нәҗипов…

Тагын бер язмамда мин бу йорттагы матур үзгәрешләрне, яңалыкларны күреп: «Ниһаять, аларда да барысы да тәртиптә дип, ничә еллар буена беренче мәртәбә сөенеп кайттым», – дигәнмен. Исәбем инде бу темага башка кайтмаска булган да… Тик район газетасында басылган бер рәхмәт хаты «Ятимлек безнең итәккә тагылган бугай инде» дигән язмага сәбәпче булган. Арбор авылына кияүгә чыккан Нурсинәләре, баласы туып озак та үтми, авырый башлый һәм бер ел дигәндә күзләрен мәңгелеккә йома. Апасы авырый башлаганнан гел янында булган Рәйсә исә, ул үлгәч, җизнәсе Камилгә һәм өлкәннәргә нәни Кәримне карарга булыша… Ә Шамил абый исә, бу хәсрәтне күтәрә алмыйча, урынга ук егыла.

– Ятимлек безнең итәккә тагылган бугай инде, – дигән иде ул чакта, әрнеп, Рәйсә. – Бездән бер дә читкә китәсе килми…

Ике елдан соң кабат, юл уңае гына Рәйсәләргә сугылып чыкканмын. Анысы исә «Ятимлек безнең итәккә тагылган бугай инде – 2» дигән язмага нигез булган. «Мин бармый торган ике ел эчендә инде Кәрим дөм ятим калган булып чыкты. Башта Шамил бабасы, аннан кан басымы күтәрелеп, кинәт кенә әтисе Камил үлеп киткән… Сиксәнгә җитеп килүче, соңгы елларда бер-бер артлы киленен, ирен, улын җирләгән Рауза апа оныгын Рәйсәгә ышанып тапшыра. Бүген Рәйсә өч яшьлек Кәрим белән тумыштан акылга җиңел абыйсы Рәдифкә – опекун, коррекцион мәктәптә укыган энесе Рәдискә «күзколак», алты айлык улы Әмиргә әни, өлкән яшьтәге туганнары Гадил абыйга үз түреннән урын биргән мәрхәмәтле җан да. Зур гаиләнең тоткасы да, терәге дә ул. Тормыш инде аны үз сикәлтәләрендә сыный-сыный чарлады, зарланмаска, уфтанмаска өйрәтте. «Шөкер»дән башка сүз әйтми Рәйсә. «Безне яңа өйле итәргә җыеналар бит әле, – диде ул, сөенеп. – Бөтен документларны тәртипләп кенә бирдем, барысы артыннан авыл советы җитәкчесе, элекке укытучым Рафил абый Җәләев йөри…» Бирсен Ходай. Бәлки яңа нигездә бөтенләй башкача – матур, бәхетле яңа тормыш башларга насыйп булыр. Алар бу бәхеткә бик лаек. Шуңа да яңа өй дигәннәре хыял гына булып калмасын иде», – дип язганмын моннан биш ел элек.

…Рәйсәне даруханәдә очраткач та, башта хәлләрен белештем, аннан: «Яңа өй хыял булып кына калмадымы?» – дип сорадым.

– Юк, без хәзер яңа өйдә яшибез бит, – диде ул, сөенеп. – Өр-яңа түгел, әмма элеккесеннән өч тапкыр зуррак, бөтен уңайлыклары да бар. Рафил абый әйткән сүзендә торды, бөтенесе артыннан үзе йөреп, хөкүмәт программасы нигезендә безне өйле итте. Бик рәхмәтле без аңа. Авылның икенче очына күченсәк тә, бик тиз ияләштек. Барыбыз да исән-сау. Улыма тиздән алты яшь тула. Кәрим быел беренче сыйныфка укырга керәсе иде. Күпме дәвалануларга йөртсәк тә, тайпылышлары бетеп җитмәде, коррекцион мәктәпкә бирергә кирәк, диләр. Районда берничә мәктәптә андый сыйныфлар бар, тик анда көн саен йөртү өчен машина кирәк. Кенәрдәге интернатка җибәрәсе булса, аңа да, безгә дә җайсыз була инде. Күрше авыл мәктәбендә дә бу уку елында шундый сыйныф ачыла икән дип әйтәләр, алай булса, бик тә әйбәт булыр иде. Балаларны көндәлек автобус йөртә бит анда.

– Туганыгыз булды, ахры, бик тәмләп сөйләштегез, – ди дару сатучы танышым.

– Туганымдай якын кешегә әйләнде шул инде бу күпне күргән бала, язмам герое ул минем, – дидем дә, нидән башларга белми тукталып калдым. Бер-ике сүзгә генә сыярлык түгел шул бу баланың күргәннәре. Бүген дә әнә дистәгә якын язмамны өстән-өстән генә хәтердән үткәрдем. Аларның һәркайсы сынаулар белән туп-тулы…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Әхмәтова** Фәйрүзә Рифкать кызы; Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары **Друк** Владимир Васильевич; Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты эшләр идарәчесе **Заглядова** Ольга Валентиновна; Татарстан Республикасының Чирмешән муниципаль районы Советы оештыру бүлеге башлыгы урынбасары **Сафина** Флера Әкъдәс кызы; Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Сарсазы авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Хәйретдинова** Рәмзия Халит кызы; күпьеллык намуслы хезмәте, гражданлык хәле актларын теркәү системасын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге башлыгы **Вәлишина** Гөлчәчәк Әмирҗан кызы; Татарстан Республикасында торак сәясәтен үстерүгә өлеш кертүе, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттырудагы казанышлары өчен «Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең архитектура, шәһәр төзелеше һәм торак үсеше идарәсе башлыгы урынбасары **Миңнегәрәева** Юлия Мансур кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«ВОСТОК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең ветеринария табибы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Габбасов** Илнур Харис улына, «ӘСӘНБАШ-АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Заря» бүлекчәсе ветеринария табибы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Максимов** Анатолий Никитичка, «Чистай район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең ветеринария табибы- токсикологы **Назарова** Вера Николаевнага, «Үзәк фәнни-методик ветеринария лабораториясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан филиалы директоры урынбасары **Садриев** Айдар Радик улына, Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе ветеринария табибы **Әбүзәров** Фаикъ Фәрит улына, «Нурлат районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе ветеринария табибы – Әлмәт ветеринария участогы мөдире **Нуретдинов** Рафис Раис улына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Татавтодор» акционерлык җәмгыятенең Саба филиалы баш инженеры **Гәрәев** Илдус Галиәхмәт улына, «Зеленодольск муниципаль районының Техник күзәтчелек хезмәте» муниципаль унитар предприятиесе директоры **Зиннуров** Рамил Наил улына, «Зеленодольск муниципаль районының Төзелеш һәм инфраструктур үсеш департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе **Мәхмүтов** Ирек Абдрахман улына, «Татавтодор» акционерлык җәмгыятенең Аксубай филиалы директоры **Сафин** Фәнис Фәсхетдин улына, «Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең Кама аръягы территориаль бүлеге баш белгече **Хәмитов** Рөстәм Сөләйман улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте Автотранспорт предприятиесенең 2 номерлы автоколоннасы автомобиль йөртүчесе **Алексеев** Виниамин Владимировичка; «Тулпар Эйр» авиакомпаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары **Хәким** Азат Мортаза улына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Бурычлы тәгәрмәч

< Ахыры. Башы 2 нче биттә

Белгеч фикеренчә, автокредитны кулда машина бәясенең ким дигәндә яртысы күләмендә акча булган очракта рәсмиләштерү отышлырак. «Автокредит рәсмиләштергәндә кредитның алдан түләп бетерү шартлары белән дә яхшылап танышыгыз. Фатирдан аермалы буларак, машина сатып алуга ук кыйммәтен югалта. Машинаның елы искергән саен, ул очсызлана бара. Шуңа күрә автокредитны булдыра алган кадәр вакытыннан алда түләп бетерергә тырышырга кирәк», – ди юрист.

Илнур Гарипов автосалоннарда еш ишетергә туры килгән процентсыз кредит дигән сүзләргә дә кызыкмаска киңәш итә. «Ул шул ук рассрочка инде. Әмма аның шартлары бик катгый. Андый процентсыз кредитны алганда, беренчедән, машинаның ярты бәясе күләмендә беренчел кертем ясарга, икенчедән, бу кредитны бер ел эчендә түләп бетерергә кирәк», – ди белгеч.

Билгеле булганча, автокредитны турыдан-туры банкта яки автосалон аша ссуда алып рәсмиләштерергә була. Банк аша эш иткәндә, күбрәк документ җыярга туры киләчәк, әмма кредитны күпкә отышлырак шартларда рәсмиләштерергә мөмкин. Автокредитны салонда рәсмиләштергәндә исә кәгазь мәшәкате азрак. Әмма биредә рәсмиләштергән кредит шартлары бик отышлы булмый. Ник дигәндә, автосалон кредит алучы белән банк арасында арадашчы ролен үти.

– Дөрес, автодилерлар кайвакыт махсус акцияләр дә оештыра. Андый чакта автокредитны күпкә түбән процент белән рәсмиләштерергә яки билгеле бер төр машинаны зур ташлама белән алырга мөмкин. Моннан тыш автосалоннарда машинага экспресс-кредит та рәсмиләштерергә мөмкин. Андый кредитны алу өчен кешенең кулында бер-ике документ булу да җитә. Кредитны хуплау-хупламаулары да бер сәгать эчендә билгеле була, – ди Илнур Гарипов. – Шунысын да истә тотарга кирәк: автокредит түләп бетергәнче машина залогта санала. Кредитны вакытында түләп бармаган очракта, банк аны тартып алырга хокуклы. Кредит түләү вакыты озаграк булган саен, «тимер ат»сыз калу куркынычы да зуррак. Үз күзәтүләремнән чыгып шуны әйтә алам: кредит белән проблемалар еш кына аны рәсмиләштерүгә үк түгел, бер-ике елдан башлана.

Аттестат о среднем техническом образовании, выданный СПТУ-67 города Ворошиловграда Республики Украина (период обучения с 1986 по 1988 г.) на имя Ахметчиной Ольги Владимировны, считать недействительным в связи с утерей.

Спорт

Президенттан хәер-фатиха

Рөстәм Миңнеханов, «Ак барс» тренерлары һәм уенчылары белән очрашып, аларга яңа сезонда уңышлар теләде.

«Барыбыз да – сезнең җанатарлар. Клуб президенты хоккей үсеше өчен барысын да эшли. Команда өчен барлык шартлар булдырылган. Иң мөһиме – имгәнмәскә», – диде Президент. Рөстәм Миңнеханов команданы балалар белән чагыштырды. «Әлбәттә, җиңәргә кирәк. Әмма килеп чыкмый икән, без барыбер бергә. «Ак барс» үз балаң кебек. Аны беркайчан да ташламыйсың. Иң мөһиме – уңыш насыйп булсын. Хәерле сәгатьтә», – диде ул.

Команданың яңа баш тренеры Олег Знарок әйтүенчә, алар алларында нинди бурыч барлыгын яхшы белә. «Ак барс»ның Татарстан өчен нинди мәгънәгә ия булганын аңлыйбыз. Кулдан килгәннең барысын да эшләячәкбез», – диде ул.

Капитан Данис Зарипов узган елгы очрашуда карьерасын тәмамларга җыенганын әйткән иде. Быел исә яңа килешү имзалады. «Бу юлы вәгъдәләр булмаячак. Барысын да бозда исбатлаячакбыз», – диде 41 яшьлек хоккейчы.

«Ак барс» яңа сезонның беренче очрашуын 3 сентябрьдә Мәскәүдә «Динамо»га каршы уздырачак.

tatarstan.ru

Мактаганга очко бирмиләр

«Рубин» рәттән икенче җиңүен яулады. Дөрес, Казан футболчылары беренче лиганың иң соңгы командасына хәлиткеч тупны өстәмә вакытта гына кертә алды. Бу атна ахырында исә Татарстан башкаласына «КАМАЗ» килә. Чаллы командасының яңа сезонда әле бер мәртәбә дә оттырганы юк.

Алдагы очрашуда үз кырында «Кубань»ны откач, «Рубин» турында уңай фикер әйтүчеләр күп булды. Күңеле төшкән тамашачы сөенде, белгечләр мактады, футболчылар үзләре өметләндерде. Болай булгач, боз кузгалды, бар да яхшы була, янәсе. «Беренче тапкыр без көткән уен сыйфаты белән нәтиҗә бергә туры килде. Нәтиҗәгә сыйфат аша омтылабыз. Иң авыры әнә шул, чөнки моңа тиз генә ирешеп булмый», – диде баш тренер Леонид Слуцкий, командасы «Кубань» капкасына өч җавапсыз туп керткәч.

Хәтта Краснодар командасының остазы Роберт Евдокимов та «Рубин»ның һичшиксез беренче урынны аласын әйтте. Ләкин бу сүзләр Казан командасының салпы ягына салам кыстыруга тиң. «Рубин»ны очкосыз калдыру өчен көндәшләр аяк-кулларыннан килгәнне дә, килмәгәнне дә эшләргә тырыша. Леонид Слуцкий уенчыларына бер генә матчта да җиңел булмаячак. Осталыклары күбрәк булса да, үзләренә карата аерым мөнәсәбәткә ияләшергә туры киләчәк.

Ульянда «Волга»га каршы узган очрашуда да шулай булды. Көндәшләр турнир таблицасында соңгы урында бара, аларның нибары бер очкосы бар. Әмма беренче лиганың иң бай командасына каршы чыккач, боларның барысы да онытылды. Казан командасы уен башында ук исәпне ачты, әмма «Волга»ның җавабы да озак көттермәде. Дөрес, «Рубин» капкасына билгеләнгән пенальтиның ни дәрәҗәдә урынлы булуы хакында озак бәхәсләшергә мөмкин. Аның каравы әле беренче тайм ахырында ук хуҗалар бер кешегә азрак калды. Шуңа карамастан, Ульян командасы 90 минутка кадәр туп керттермәде. «Рубин» өстәмә вакытта гына уңышка ирешә алды. Голның авторы – Джоэль Фамейе. Бу – аның бишенче тубы һәм ул беренче лигада иң нәтиҗәле уенчылар арасында беренче урынга чыкты.

Әлеге очрашудан соң «Рубин» турнир таблицасында өченче урынга күтәрелде. Ә бу якшәмбедә Казанга «КАМАЗ» килә. Бу уенда бер төбәк командалары арасындагы көндәшлек кызулыгы да нык сизеләчәк. Җитмәсә, Чаллы футболчылары турнир таблицасында беренче урынны били.

	команда	очко
1	КАМАЗ	16
2	Алания	14
3	Рубин	11
4	Балтика	11
5	Волгарь	11
6	Енисей	11
7	Арсенал Тула	9
8	Динамо Махачкала	9
9	Нефтехимик	8
10	Уфа	8
11	Кубань	7
12	Краснодар-2	7
13	Родина	6
14	СКА Хабаровск	5
15	Шинник	5
16	Акрон	4
17	Велес	3
18	Волга Ульян	1

rubin-kazan.ru

almetteatr.ru

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КИЛӘЛӘР!

ӘЛМӘТ ТЕАТРЫ КАЗАНДА «ҖИЛ АРТЫННАН» СПЕКТАКЛЕН КҮРСӘТӘЧӘК

Ерагаймасын ара, дип, ел да Казан тамашачысы белән очрашып тора алар. Әлмәт театры турында әле сүзебез. Тәҗрибәләрдән курыкмый торган театр узган сезонда әфган язучысы әсәрен сәхнәләштергән иде. Нәтиҗәдә ул спектакль республикада да, Кече шәһәрләр театрлары фестивалендә дә иң яхшысы дип табылды. Инде безгә дә барып күрергә җай чыкты.

Спектакльнең уңышлы булуы турында «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында Әлмәт театры директоры Фәридә Исмәгыйлева да әйтте.

– «Җил артыннан» – Татарстандагы узган елгы театраль сезонның уңышы ул. «Тантана-2022» республика театр премиясендә «Зур формалы иң яхшы спектакль» номинациясендә җиңүе дә, Кече шәһәрләр театрлары фестивалендә гран-прига лаек булуы да шуны раслый, – диде ул. – Быел Казанга зур гастрольләр белән килергә уйламадык. Берәр спектакль белән берничә тапкыр килергә исәпләп торабыз. Очрашу урыны – Камал театры.

«Җил артыннан» спектакленең режиссеры – Россиянең халык артисты Камил Тукаев. Авторы – Америкада яшәп иҗат итүче әфган язучысы Халед Хоссейни. Инсценировка авторы – драматург Меттью Спенглер.

Шулай итеп, «Җил артыннан» спектаклен 22 сентябрьдә 19.00 сәгатьтә күрсәтәчәкләр. 26 ноябрьдә Казан тамашачысы Гаяз Исхакый әсәре буенча режиссер Айдар Җаббаров куйган «Ул әле өйләнмәгән иде» спектаклен карый алачак. Яңа елдан соң әлмәтлеләр Зөлфәт Хәкимнең «Ана җыры» әсәре буенча куелган спектакльләрен алып килергә ниятли. Кем белә, тамашачы җылы кабул итсә, бәлки, тагын килерләр. Үзләре бер дә каршы түгел.

Әлмәтлеләр 78 нче сезоннарын октябрь башында Илгиз Зәйниевнең «АХ, яки Мәхәббәт элмәге» комедиясе белән ачарга җыена. Фәридә Исмәгыйлева әйтмешли, театрлар, соңгы арада комедияләрдән бөтенләй диярлек читләшеп, халыкны көлдерүдән бизә язды. Елмаеп, көлеп яшәү җиңелрәк шул, чыннан да.

Үзгәрү

Янә спектакльгә кайтыйк. Әмир ролен башкаручы Динар Хөснетдинов аның уңыш серен болайрак аңлатты:

– Миңа калса, әлеге спектакльдәге һәр күренеш үзәккә үтә, тамашачыларның тормышын чагылдыра. Мондагы геройлар кичергәнне тормышта һәркемгә кичерергә туры килә бит. Кызганыч, беребез дә гомер юлын ялгышсыз узмый.

Динарга спектакльне куйганда күләмле текстны ятлау авыр булган. Ә Хәсән һәм Сохрәб рольләрен башкаручы Айрат Мифтаховка исә 40 көн эчендә 8 килога ябыгырга туры килгән.

– Дөресен генә әйткәндә, мин бу рольне 10 ел буе көттем. Башка рольләремнән зарланмыйм, әмма күңелгә нидер җитми иде. Нинди дер зуррак, җитдирәк рольгә алынасым килде. Шуңа да бу рольләремә ныклап «ябыштым». Үз өстемдә эшләргә туры килде. 75 килодан 67 килога калдым, чөнки роль өчен «җыелырга» кирәк иде, – диде актер. – Хәсән белән Сохрәб – икесе ике төрле кеше. Бер рольдән икенчесенә күчү җиңел булмады.

Спектакльдә тискәре рольне башкаручы Раушан Мөхәммәтҗановка исә үзе белән шактый көрәшергә туры килгән. Бер мәлне рольдән баш тартырга да уйлаган ул.

– Әлеге романны укыганым бар иде. Бездә куелачагын белгәч, геройларны барладым. Нишләптер үземнең явыз Асефны уйныйсым килде. Һәм режиссер мине сайлады да. Беренче мәлләрдә шундый авыр булды миңа. Холкым буенча бик нечкә күңелле мин. Ә Асеф – киресенчә, каты бәгырьле, кешеләрне рәнҗетә торган образ. Ничек итеп уйнармын, дип борчылдым, – дип сөйләде Раушан.

Динар Хөснетдинов исә дустының хәтта төшенкелеккә бирелүен дә сөйләде. Әмма барыбер уйнап чыккан ул Асефны. Әле ничек кенә бит!

– Спектакльне Кече шәһәрләр театрлары фестивалендә күрсәткәннән соң, жюри рәисе, танылган драматург, режиссер Николай Коляда, җил-җил атлап, кычкыра-кычкыра: «Где он, этот гнида? Сейчас я его убью!» – дип кереп җитте. Аптырадык. Раушанны эзли икән, – дип искә алды Фәридә Исмәгыйлева.

Баксаң, Николай Колядага Раушанның Асефы бик каты тәэсир иткән икән. Төн йокыларын качырган хәтта. Тормышта бөтенләй башка төрле булуын күргәч, кичергән тагын үзе. Һәм Әлмәт театрына гашыйк булган. Алай булгач, без дә килик, күрик!

ҖЫРЧЫЛАР УРАМГА ЧЫКТЫ

Татар эстрадасының иң популяр җырчылары, интерактив ярышлар һәм истәлекле бүләкләр. «Татар радиосы»ның 21 «яшь»лек туган көне уңаеннан, «Казан» гаилә үзәге каршында ачык һавада зур концерт узды. Бәйрәмне без дә күреп кайттык.

«Барс медиа»ның матбугат хезмәте

Беренче тапкыр ачык һавада концерт 2001 елда Галиәсгар Камал театры каршында узган. Соңгы ике елда мәгълүм чикләүләр аркасында үткәрелмәгән. Быел «Татар радиосы» күркәм традициясен кабат яңартып җибәрде һәм мондый төр чараларны сагынып өлгергән тамашачыларын сөендерде.

Радионы туган көне белән котларга татар эстрадасының 30га якын артисты килгән иде. Алар арасында Булат Бәйрәмов, Ләйсән Гыймаева, Ильмира Нәгыймова, Марат Яруллин, Ришат Фазлыйәхмәтов, Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар, Айдар Рәкыйпов, Булат Нигъмәтуллин, Гөлназ һәм Илсур Шәрипҗановлар, Илшат Сафин, Рәзил Камалов һәм Рәфинә Ганиуллина, Зәринә Асылкаева һәм башка бик күп популяр җырчылар бар. Махсус кунак итеп Фирдүс Тямаевны чакырганнар иде. Һәр артист үзенең иң популяр, халыкның мәхәббәтен яулаган җырын бүләк итте.

Быел 20 меңнән артык тамашачы җыелган. Чып-чын бәйрәм рухы хөкем сөрде бу кичәдә. Популяр хитлар, тамашачы белән аралашу, дәртле биюләр бер генә кешене дә битараф калдырмагандыр. Дүрт сәгатькә якын барган тамаша дәвамында халык биеде, җырчыларга кушылып җырлады, рәхәтләнеп күңел ачты.

Тамашаны традицион рәвештә «Татар радиосы» диджейлары алып барды. Ахырына якынлашканда, сәхнәгә «Татар радио»сының баш мөхәррире Рамил Шәрәфиев һәм Татарстанның атказанган артисты Гөлназ Сәфәрова чыкты.

– Җәй буе әзерләндек. Бүгенге концерттан мин бик канәгать. Кеше бик күп килгән. Бу, һичшиксез, сөендерә, – диде Рамил Шәрәфиев.

Концерт «Балалы солянка» балалар премиясе лауреатлары Әминә һәм Мәдинә Рәсуловалар, Милина Хәйруллина, Айза Галиева, Наилә Славина, Җәмилә Әсәдуллина белән Илгиз Шәйхразиев дуэты чыгышларыннан башланып китте. Соңрак татар эстрадасының өлкәнрәк йолдызларына да чират җитте.

Музыкаль кичә нәрсәләр белән истә калды соң? Алмаз һәм Зөлфирә Мирзаяновлар өр-яңа «Яннарымда ул булганда» дип исемләнгән җырларын тәкъдим иттеләр. Халык яратып кабул итте. Әле беренче тапкыр ишеткән җырга бии-бии кушылып җырлаулары шул хакта сөйли. Илнат Фәрхуллин, Булат Бәйрәмов һәм Ләйсән Гыймаева, Ришат Фазлыйәхмәтов, Ильмира Нәгыймова, Радик Яруллин һәм Айрат Сафин, Айдар Рәкыйпов та халыкның көчле алкышларына күмелделәр. Әлеге кичәдә күпләр яратып өлгергән Шәрәпҗанның «Красопетка»сын, Ләйсән һәм Булат Гыймаевларның олы кызлары Таңсылуның тәүге тапкыр зур сәхнәдә чыгыш ясавын, яшь иҗади пар Лия Шәмсина белән Артур Маузерның Татарстанның халык артисты Әлфис Кыямов репертуарыннан «Кил син» җырын башкаруын да ишетте тамашачы.

«Татар радиосы»ның туган көненә җыелган кешеләр бушлай концерт кына карап калмады, истәлекле бүләкләр белән дә кайтып китте. «Татар радиосы» төркеме бәйрәм кунаклары өчен махсус уен-ярышлар әзерләгән иде. Интерактив уеннарда катнашкан һәрбер кешегә иганәчеләр тарафыннан бүләкләр тапшырылды.

Кичәне Татарстанның атказанган артисты Фирдүс Тямаев тәмамлады. Концертның урталарында ук тамашачыларның «Әйдә Тямай!» дигән сүзләре ишетелгән иде инде. Җиденче яртыда килгән халык таралышмады, ахырга кадәр яраткан җырчысын көтте. Тамашачы Гөлназ ханым да иң элек аның өчен килгән.

– Бүген рәхәтләнеп күңел ачарга, иң яраткан җырчыларыбызны күрергә килдек. Ачык һавада концертлар сагындырган. Фирдүс Тямаев та була дигәч, аеруча шатландым. Аның энергетикасы бөтен залны тутыра, – дип, тәэсирләрен уртаклашты ул.

Фирдүс исә халыкны биетеп һәм җырлатып кына калмады, махсус хәрби операциядә катнашучы Татарстан егетләрен дә искә алды, аларның исән-сау әйләнеп кайтуларын теләде.

«Татар радиосы» һәрвакыттагыча яхшы кәеф бүләк итте, кыскасы. Казанлылар өчен әлеге музыкаль бәйрәм бу җәйнең иң күңелле кичләренең берсе булып истә калыр.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6688 данә
Гомуми тираж – 15838 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 322

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+